| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.07.2023 с.Старое Дрожжаное № 255

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында Мәгариф өлкәсендә вәкаләтләр бүлешү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законның 7 статьясына һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 41 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 13 июнендәге 256-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 17 мартындагы 135 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында Мәгариф өлкәсендә вәкаләтләр бүлешү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**3.27 пункты** түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«- гамәлгә ашырыла торган мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлегенең дәүләт аккредитациясе булу яисә булмау турында;»;

**3.28 пунктта дүртенче абзацны** төшереп калдырырга;

**3.31 пунктта** түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма укучыларга әлеге оешмада булган чорда беренче ярдәм күрсәтүне оештыруны тәэмин итә. Беренче ярдәмне Россия Федерациясенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге законнары нигезендә педагогик хезмәткәрләр һәм башка затлар тиешле әзерлек һәм (яисә) күнекмәләр булганда күрсәтергә хокуклы.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ф. Заляловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов